Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлегенең
Каськиавылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

26 ноябрь 2022 ел № 4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, 2022елның 26 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта булганграждннарның җыен нәтиҗәләре нигезендәтүбәндәге “Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловка авыл җирлеге Каськи авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 8900 сум күләмендә үзара салым кертүһәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрүгә юнәлдерү белән килешәсезме: “1) спорт мәйданчы сатып алу, спорт мәйданчыгы территориясен төзекләндерү, кышкы һәм җәйге айларда карап тоту, смета төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү; 2) территорияне төзекләндерү, смета төзү, техник күзәтчелек үткәрү өчен түләүгә ризамы?” соравы буенчагражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 20 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 12 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 12 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карарбирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Иске Михайловкаавыл җирлегенең Каськи авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2.«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының авыл Иске Михайловка җирлеге Каськи авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 8900 сум күләмендә үзара салым кертүһәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару: ““1) спорт мәйданчы сатып алу, спорт мәйданчыгы территориясен төзекләндерү, кышкы һәм җәйге айларда карап тоту, смета төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү; 2) территорияне төзекләндерү, смета төзү, техник күзәтчелек үткәрү өчен түләүгә” турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Каськи авылы, Полевая урамы, 20а йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә,«Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендәӘлмәт муниципаль районы сайтында«Интернет»мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Н.А.Миназева